ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ГЫЙНВАР,
2017 нче ел

№5 (20)

ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!






11— Халыкара
“РӘХМӘТ” көне
25—Студентлар
көне

## ЯВА КАРЛАР, ЯҢА КАРЛАР…

Бөтен дөньяны ап-ак кар каплады. Табигать җем-җем итеп торган яңа матур күлмәген киде. Агачлар да җылы мамык шәлләрен ябынды. Елгалар, күлләр көзге кебек шома боз белән капланды. Урманкырлар өстендә тантаналы тынлык. Кыш көне көннәр кыска, салкын. Без, балалар, чаңгы-чанада, тимераякта шуабыз. Безне көннең салкынлыгы да куркытмый. Безнең тавыштан урам шау-гөр килеп тора. Кыш — иң матур ел фасылларының берсе. Туган ягыбызның кышкы табигате бигрәк матур.




## Кышкы ялымның бер көне

Менә сагынып көтеп алган кышкы каникуллар да килеп җитте. Сөенеч өстенә сөенеч өстәп, Кыш бабай тәмле күчтәнәчләрен өләшеп чыкты. Матур күлмәген кигән, матур итеп бизәлгән чыршы-сылукай да кунакка килде…

Менә без Динара белән урамга чыктык. Бергәләп тау ясадык. Киемнәребез юешләнгәнче рәхәтләнеп тау шудык. Ә аннары Кар бабай ясадык. Түгәрәк кар шарларын берсе өстенә икенчесен куя алмыйча шактый азапландык. Динара кечкенәрәк бит әле, укырга да кермәгән.

Тәрәзәдән безне әнием күзәтеп торган. Әллә безне кызганып, әллә үзе дә кызыгып киткән, кар шарларын куешырга әнием дә булышты. Аннары күмердән күзләрен, кишердән борынын куйдык. Башына чиләк кигертеп, кулына себерке тоттырырга да онытмадык. Кар бабаебыз бик килешле килеп чыкты. Соңыннан кар атышып уйнадык. Без уйнаганда ябалак –ябалак кар яварга тотынды. Табигать тагын да матурланды. Минем кышкы ялымның бер көне шулай бик күңелле узды!

**Закирова Диана**

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Математика фәнен белүнңне исбатла! | 2 |
| Стресстан котылып буламы? | 3 |
| Якыннан танышыйк! | 4 |
| Алтын куллар! | 5 |
| Әкияттә кунакта | 6 |
| Акция “Яркая, здоровая зимушка -зима!» | 6 |
| Котлыйбыз! | 7 |

# "ЧТО И ТРЕБОВАЛОСЬ ДОКАЗАТЬ". МАТЕМАТИКА ФӘНЕН БЕЛҮЕҢНЕ ИСБАТЛА!

**Фәннәр патшабикәсе булган математиканы ни дәрәҗәдә яхшы үзләштергәнеңне беләсең килсә, 11 мартта контроль эшкә кил! «Что и требовалось доказать» дип исемләнгән эшне КФУда яки өйдән чыкмыйча да эшләп була.**

Контроль эш 10 биремнән торачак. Аларны чишәр өчен мәктәп белеме дә җитә. Шуңа да анда һәркем катнашырга мөмкин. Чараның сайтында биремнәрне 11 мартта 12.00дән башлап бер тәүлек дәвамында алып булачак. Ә вузда эшләргә теләсәгез, алдан теркәлеп кую яхшырак. Биремнәрне эшләр өчен 1 генә сәгать вакыт бирельчәк. Белешмә: «Яндекс» «Что и требовалось доказать» дип исемләнгән контроль эшне инде өченче тапкыр уздыра. Былтыр анда Россия, Белруссия, Украина, Казахстан һәм башка илләрдән 24 меңнән артык кеше катнашкан. Казан катнашучыларының яртысы гына контроль эшен башкарып чыга алган. 36 процент кеше «3»ле алган, «4»ле билгесенә 16 процент кеше лаек булган. «5»ле бары тик 8 процент кешегә генә тәтегән.

**Кайчан?** 11 мартта, сәгать 12.00дән башлап, бер тәүлек дәвамында

**Кайда?** Казан федераль университетында яки онлайн рәвештә.




**1 мартта Татарстанның барлык мәктәпләрендә һәм гимназияләрендә «Табигать дәресе» узачак.**

Ул Татарстанда Экология һәм иҗтимагый киңлекләр елына багышлана. Бу хакта Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр итә.

Дәрестә укучыларга викторина һәм уен формасында табигатькә сак карашның мөһимлеге турында җиткерәчәкләр. Чараның төп максаты – укучы балаларга табигатькә зыян салмау гына түгел, аны саклау мөһимлеген дә аңлату.

**Мәктәп администрациясе**

## Олимпиада — тырыш һәм сәләтлеләр бәйгесе

Ниһаять, район олимпиадалары да тәмамланды. Безнең мәктәп укучылары да үзләрен тиешле дәрәҗәдә күрсәтте . Рус теленнән Әһлиуллин Аяз, татар теле һәм татар әдәбиятыннан 2 призлы урын! Ә иң күңеллесе, район күләмендә БЕРЕНЧЕ урын бездә бит! Афәрин! Республика күләмендә дә укучыларыбыз Шарапова Ләйсән , Гафурова Алия, Әһлиуллин Аяз сынатмаслар. Районыбыз данын яклаган укучыларыбызга ныклы сәламәтлек, яңа уңышлар теләп калабыз!

## *25 нче гыйнвар — Студентлар көне*




**ИГЪТИБАР!**

Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы искәрткәнчә, дәресләр түбәндәге очракта кичектерелергә мөмкин: шәһәрдә 1-4 сыйныфлар һава торышы –25 градус булганда, авылларда –23 градус булганда укырга килми; 5-9 сыйныфлар шәһәрдә –27 градус булганда, авылда –25 градус булганда, ә 10-11 сыйныфлар шәһәрдә –32 градус булганда, авылда –30 градус булганда мәктәпкә бармаска хокуклы.

## Якыннан танышыйк!





**Укучыларның сорауларына физика һәм технология укытучысы Абдрахманов Рәис Азатович җавап бирә.**

**- Рәис Азатович, мәктәп бусагасын яңа гына атлаган балада укырга теләкне ничек уятырга?**

Балада уку теләге тусын өчен һәрбер малай-кызның холкын исәпкә алу, аларның һәркайсы белән җылы мөнәсәбәт урнаштыру мөһим. Аннары, бар баланың үз сәләте була. Укытучы шул сәләтне күреп, аны тагын да үстерергә, кирәк чакта ярдәм итәргә тиеш. Һәм инде, әлбәттә, балаларны яратырга кирәк, балалар яратмаган кеше, гомумән, мәктәптә эшли алмый. **- Соңгы елларда мөгаллимнәрнең хезмәт хакы шактый артты. Укытучының авыр хезмәте тиешенчә бәяләнергә тиеш дип кабатлый торгач, ниһаять, вәзгыять үзгәрде...**

- Әйе, сөенечкә, хәзер хезмәт хакына зарланырлык түгел. 10-20 ел элек укытучыга түләнгән хезмәт хакы турында искә дә төшерәсе килми. Ул чакта мәктәпкә үз эшенә чын мәгънәдә бирелгән, балаларны яратучы кешеләр генә килә иде

**- Укытучы эшенең төп авырлыклары нәрсәдә бүген?**

— - Бер яктан, укытучы эше җиңеләйде хәзер. Бик күп методик әсбаплар басыла. Заманча технологияләр дә эшебездә бик зур ярдәм. Икенче яктан, соңгы елларда кәгазь эше артты.

Укытучы дәрескә әзерләнү урынына документлар тутыра, хисаплар яза. Бу проблема турында даими әйтелеп килә, хезмәт хакы мәсьәләсе кебек монысы да хәл ителсә, бик яхшы булыр иде.

**— Бүгенге балалар иң кечкенәдән үк заманча технологияләрне үзләштерә. баланы уку белән кызыксындырып җибәрү өчен бик нык тырышырга туры киләдер...**

Белем бирү процессын кызыклы итү өчен шул ук заманча технологияләрне кулланабыз. Укытучылар өчен махсус курслар оештырыла, яңача эшләү өчен шартлар да тудырыла. Әйтик, хәзер һәр бүлмәдә интерактив такталар, проекторлар урнаштырылган. Дәресне җанландырып җибәрү өчен рәсемнәр, презентацияләр күрсәтеп эш итәм.

**Рәис абый, әңгәмәбез өчен зур рәхмәт!**

**Әңгәмәне Рузилә Садртдинова алып барды**

**Мәктәп, контроль эш, имтиханнар… Никтер шушы исемлек ахырына стресс сүзен дә өстәп куясы килә. Белгечләр фикеренчә, стресс кеше тормышына иртә таңнан – будильник шалтыравы белән үк килеп керә.**

Аннан инде барысы да алдан корылган схема буенча бара: транспорттагы этеш-төртеш, пробкалар, уку яки эш. Өстевенә конфликтлар, йокы җитмәү һәм башка шуныңише проблемалар кушыла. Арабызда стресска бик тиз бирешүчеләр дә, аның алдында баш имәүчеләр дә байтак. Беренче исемлектән – икенчесенә һәм, киресенчә, икенчесеннән беренчесенә күчүчеләр дә очрарга мөмкин. Бүген без синең стресска ни дәрәҗәдә чыдам булуыңны тикшереп карарга уйладык. *Моның өчен сиңа 10 сорауга җавап бирергә генә кирәк. Җаваплар түбәндәгечә бәяләнә: "юк" – 0 балл, "әйе, һичшиксез" – 3 балл, "әйе, кайчакта" – 1 балл.*

**Санап киткән сәбәпләр сине чыгырдан чыгарырга мөмкинме?**

1) Көчле ислемай исе.
2) Дустыңны, сыйныфташыңны озак көтү.
3) Кемнеңдер сәбәпсез көлүе.
4) Әти-әниең, укытучыларның нәрсәдер өйрәтүе.
5) Транспорттагы шау-шу.
6) Аралашу вакытында кулларын селки-селки сөйләүчеләр.
7) Сиңа кызыксыз һәм кирәк булмаган әйбер бүләк итүләре.
8) Укыйсың килгән китапның эчтәлеген алдан ук сөйләп бирүләре.
9) Кинотеатрда алдагы рәттәгеләрнең сөйләшеп, боргаланып утырулары.
10) Синең алдыңда тырнак кимерүләре.



**Нәтиҗә:**

1) 26-30 балл – син көчле стресс кичерәсең,
2) 15-26 балл – син стресска бирелүчән түгел, вак-төяккә исең китми,
3) 15 тән азрак балл – син бик тыныч, стресс сүзе сиңа гомумән таныш түгел.

Алтын куллар

# Җимлек ясыйбыз



*Ямьле яз айларында безнең яныбызга җылы яклардан нәни дусларыбыз – кошлар әйләнеп кайта. Әлбәттә, аларга нәкъ менә бу вакытта азык табу шактый авыр. Без аларга ярдәм итәргә тиешбез. Моның өчен, әйдәгез, иң гади җимлекләр ясап карыйк.*

Җимлек ясау ысуллары бик күп. Мәсәлән:

**1** 5 литрлы пластик су савыты күргәнең бардыр. Шуның аскы бер җирендә 20-25 сантиметрлы «ишек» ясарга кирәк. Кайчы белән иплән кенә шуны кис (олылар ярдәм итсә дә була), шешәнең төбенә җим (ярмалар, көнбагыш, ипи валчыклары һ.б). салып куй. Шешәне берәр агачка бау ярдәмендә (рәсемдәгечә) бәйлә.



**2** Икенче ысул шулай ук җиңел: олылардан 1,5 литрлы банка (яки пластик шешә) сорап ал. Банканы яны белән агачка элеп куй, баулар белән беркет. Сак бул, җил җимлегеңне ватарлык булмасын. Шешәне шулай ук ян ягы белән элеп куеп та була.

**3** Өченче җимлекне эшләр өчен сыңа катыргы савыттан ясалган йогырт, кефир яки сөт тартмалары кирәк булыр. Тартманың бер ягына 10-15 сантиметрлы «тишек» ясыйбыз, җим салып, кошларга җайлы бер җирдә урнаштырабыз.

Күрәсеңме, кошкайларга өйләр ясау бик җиңел. Фантазияңне кулланып, син үзең дә җимлек ясауның яңа ысулларын таба аласың. Уңышлар!



ЖИМЛЕК - кормушка - rack ['рэкъ]
ЖИМ - корм (для птиц) - fodder ['фо дэръ]
ЫСУЛ - способ - manner ['мэ нэръ]




# НИЧЕК ШӘП ПРОЕКТ ӘЗЕРЛӘРГӘ?




Хис-эмоцияләр борынгы чорлардан ук кеше тормышында бик әһәмиятле роль уйныйлар. Алар безне һәр җирдә: кибеттә дә, йортта, урамда да эзәрлекли. Һәм аңлашыла ки, үз проектыңны яки продуктыңны әзерләгәндә (хәтта бу синең мәчең турында бер кечкенә презентация генә булса да) кеше эмоцияләренә тәэсир итүнең төп аспектларын исәпкә алырга кирәк. Түбәндә бу яхшы хисләрне уятучы ысуллар китерелгән:

- Шатлык (гадәттә, аны эт, песи балалары, нәни сабыйлар уята);
- Көтелмәгәнлек (ниндидер көтелмәгән һәм күңелле әйбер эшләгез);
- Бердәнберлек-уникальлек (башка охшаш нәрсәләрдән аерылып тору);
- Игътибар күрсәтү (сез, тиеш булмасагыз да, ярдәм тәкъдим итәсез);
- Үз-үзенә тартып тору;
- Көтеп алу (үзегезнең продуктны чыгарыр алдыннан, аның хакында берәр кызык мәгълүмат җиткерегез);
- Эксклюзив булу (билгеле бер кешеләр төркеменә эксклюзив тәкъдим ясагыз);
- Тиз реакция (үз аудиториягезнең халәтенә тиз арада игътибар бирү сәләтен күрсәтегез, бигрәк тә, сездән беркем берни көтмәгәндә).

Маслоуның кеше ихтыяҗлары пирамидасы буенча, без сезнең проект өчен кайбер аспектларны аерып чыгара алабыз. Болар - функциональлек, ышанычлылык, уңайлы куллану, тышкы күренеш. Нәкъ менә шушы тәртиптә.

Яңа әйбер ясаганда, эшегезнең төп үзенчәлеген табыгыз. Аны яхшылап

эшкәртегез һәм кешеләр сезнең башкалар кебек түгел икәнегезне истә калдырырлык итегез. Сез һәм сезнең эш үзенчәлекле. Киләчәктә бу үзенчәлеккә таяныгыз һәм проектның үз сыйфатын һәм үз стилен булдырыгыз. Эшегез дөнья күргәч, барлык сорауларга җавап бирергә әзер булыгыз. Сезнең проект камил һәм ышанычлы булсын. Шулай ук, ресурсыгызны тиз арада тәэмин итегез (әгәр сезнең эшкә бу кирәк икән). Әлеге киңәшләрне кулланган һәм бик шәп булган компанияләр: Apple, Twitter, Porsche һәм башкалар.

**Һәм тагын... кешеләр сезнең эшегезне зарыгып көтерлек итегез. Дөнья күргәнче, аның исеме азмыкүпме билгеле булсын, тик артыгын кыланып ташламагыз...**

**Уңышлы проектлар телим!**

**Педагог– оештыручы**
**Фидлия Билданова**

## БДИ: үзгәрешләр дәвам итә

1. Тарих, җәмгыять белеме, география, информатика һәм мәгълүмат технологияләре буенча җавапларны сайлап алу өлеше юкка чыгарылачак.
2. Контроль-үлчәм материалларын (КИМ) имтихан пунктларында бастыру мөмкин булачак. Быел тәҗрибәдә Әгерҗе, Азнакай, Актаныш, Баулы, Бөгелмә, Ютазы, Чүпрәле районнары катнаша.
3. Тугызынчы сыйныф укучылары математика, рус телләреннән тыш, тагын ике фәннән ирекле сынау сайларга тиеш. Ирекле имтиханнардан укучы "2ле" алса да, быел ул аттестатка йогынты ясамаячак. Киләсе елда исә начар билге алучыларга әлеге документ бирелмәячәк.
4. Татарстанда тугызынчы сыйныф укучыларына чыгарылыш имтиханнарын татар телендә тапшыру өчен бернинди каршылыклар да юк. Быел сигез фәннән имтиханнарга әзерләнү өчен материаллар, ягъни демоверсияләр татарчага тәрҗемә ителгән. Алдан тапшыру этабы 21 март – 6 май көннәренә билге¬ләнгән. Ә төп этап 26 майдан 30 июньгә кадәр дәвам итәчәк.

**БДИ да укучылар тупларга тиешле минималь баллар күләме узган елдагы кебек кала. Укучыларга рус теленнән, ким дигәндә – 36 , профиль дәрәҗәдәге математикадан – 27, физика, химия һәм биологиядән -36, информатика һәм мәгълүмати – коммуникацион технологияләр буенча иң киме – 40, тарихтан һәм рус әдәбиятыннан – 32, географиядән – 37, җәмгыять белеменнән – 42, чит телләрдән 22 балл җыярга кирәк.**

**Бердәм дәүләт имтиханының төп дулкыны 30 нчы майдан 23 нче июньгә кадәр узар дип көтелә.**



В рамках реализации Республиканского антинаркотического проекта члены ШУС «Юность» совместно с отрядом «Барс» «SaMoStоятельные дети» провели акцию **«Яркая, здоровая зимушка-зима».** Акция была проведена в целях популяризации активного, позитивного здорового способа организации собственного досуга на территории школьных дворов среди учащихся 1-6 классов.




**7 февраля в Нурлате пройдет всероссийская акция «День сдачи ЕГЭ с родителями».**

В рамках акции родители смогут сами пройти всю процедуру Единого госэкзамена и попробовать сдать ЕГЭ по русскому языку. Родители нурлатских школьников сдадут ЕГЭ.



22 нче гыйнвар көнне мәктәбебезгә район мәгариф бүлеге каршында эшләүче ППМС үзәктән психологлар килде . Алар укучылар белән шәхси консультацияләр,төрле тренинглар, 9,11 сыйныф укучылары өчен "ОГЭ, ЕГЭ га психологик әзерлек" һәм 1нче класска керүчеләрнең мәктәпкә әзерлеген өйрәнделәр.

### Игелек кылу рәхәт!

Педагог - оештыручы Билданова Фидалия Вазировна һәм озайтылган көн группасы җитәкчесе Галлямова Гөлүсә Фоадовна белән берлектә, авылыбыздагы әби -бабайларга көчебездән килгән кадәр ярдәм иттек. Ялгыз яшәүче Гилязова Гөлсем әби белән Минегулова Сщрфия әбиләргә йорт тирәләрен кардан чистартырга булыштык. Мохтаҗларга билгеле бер чаралар узганда гына ярдәмгә ашыкмыйк, ә ел дәвамында ярдәмләшеп яшик. **Игелек кылу рәхәт икән!**





**Хөрмәтле**

**Абдрахманов Рәис Азатович!**

Сезне алтын юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм туачак оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!

**Гыйнвар аенда туучы кадерле укытучыларыбыз:**

**Әхмәтова Рузилә Әсхат кызы,**
**Замалеев Айрат Каим улы,**

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!

Гыйнвар аенда туучы
кадерле укучыларыбыз:

Хәлиуллин Инсаф, Стадник Динара, Садртдинов Айдар, Абдрахманова Рәзилә, Хайбуллин Айдар, Шарапова Ләйсән!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**


**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Таһирова Гайшә

**Дизайнер**: Хайбуллина Алсу

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә, Ситдикова А.лсинә, Ахметова Нәзилә.